**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 28 апрель № 257

г. Казань

Суд карарларын үтәү өчен торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен билгеләү турында

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясы нигезендә (2015 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә булган, 31 декабрьне дә кетеп, редакциясендә) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына торак урыннарга мохтаҗлар дип танылган, 2015 елны 1 гыйнварына кадәр исәпкә баскан Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты белән каралган исемлектә күрсәтелгән авыр формадагы хроник авырулардан интегүче инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән авыр формадагы хроник авырулардан интегүче инвалид балалары булган гаиләләргә (алга таба – инвалидлар, инвалид балалары булган гаиләләр), өстәмә торак мәйданына хокукны исәпкә алып, торак урын алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү буенча вазыйфалар йөкли торган законлы көченә кергән суд караларының (алга таба – суд каралары) үтәлешен тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Түбәндәгеләрне билгеләргә:

судлар карарларын үтәү өчен инвалидларга, инвалид балалары булган гаиләләргә торак урыны сатып алырга бирелә торган торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен исәпләү өчен торак урынының гомуми мәйданы нормативы 18 кв.метр тәшкил итә;

инвалидлар һәм инвалид балаларның «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 17 статьясындагы 6 өлештә каралган торак урынының өстәмә мәйданына хокуклары булганда торак урыны сатып алырга бирелә торган торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен исәпләү өчен торак урынының өстәмә мәйданы нормативы 15 кв.метр тәшкил итә;

торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме кушымта нигезендә исәпләнелә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 апрель, 257 нче карарына кушымта

Торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләмен исәпләү

Торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) күләме түбәндәге формула буенча исәпләнелә:

$$С = N_{\text{гомуми мәйд.}} \text{ х СРС} + N_{\text{өстәмә торак мәйд.}} \text{ х СРС},$$

монда:

$N_{\text{гомуми мәйд.}}$ – торак субсидиясе күләмен исәпләү өчен торак урынның гомуми мәйданы нормативы;

УББ – Татарстан Республикасы буенча торакның гомуми мәйданының 1 кв. метрына Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтләр биргән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән, 2015 елның IV кварталында гамәлдә булган уртача базар бәясе;

$N_{\text{өстәмә торак мәйд}}$ – торак субсидиясе күләмен исәпләү өчен торак урынның өстәмә мәйданы нормативы.

________________________________